КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 13 декабрь г.Казань № 1215

Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында

Татарстан Республикасының Питрәч муниципаль районында «Казан – Шәмәрдән» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында, Россия Федерациясе Җир кодексының VII бүлегендәге 49 статьясы, VII[1] бүлеге, Россия Федерациясе Граждан кодексының 279 һәм 281 статьялары, Татарстан Республикасы Җир кодексының 3 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын раслау турында» 2011 ел, 21 февраль, 134 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Татарстанның юл-транспорт комплексын карап тоту һәм үстерү баш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Татарстанның юл-транспорт идарәсе) Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында «Казан – Шәмәрдән» төбәк әһәмиятендәге автомобиль юлын реконструкцияләү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен бу карарга теркәлгән исемлек нигезендә «Ак Барс Питрәч» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте милкендәге (алга таба – алына торган җир кишәрлекләре милекчесе) 182 760 кв.метр гомуми мәйданлы җир кишәрлекләрен (алга таба – алына торган җир кишәрлекләре) алу турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына түбәндәгеләрне законнар белән билгеләнгән тәртиптә тәэмин итәргә:

10 көн эчендә:

бу карарны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыруны;

бу карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районындагы Ленино-Кокушкино авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын рәсми бастырып чыгару (халыкка белдерү) өчен билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгаруны;

бу карарның күчермәләрен алына торган җир кишәрлекләре милекчесенә, «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстанның юл-транспорт идарәсенә җибәрүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен түләү күләмен билгеләгәннән соң 30 көн эчендә, Татарстанның юл-транспорт идарәсе белән берлектә, Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен җир кишәрлекләрен алу турында килешү (алга таба – килешү) әзерләүне һәм аны алына торган җир кишәрлекләре милекчесенә җибәрүне;

килешү төзүне;

алына торган җир кишәрлекләре өчен акча түләүне;

алына торган җир кишәрлекләренә Татарстан Республикасы милке хокукын дәүләт теркәвенә алуны;

алына торган җир кишәрлекләре милекчесе тарафыннан имзаланган килешү законнар белән билгеләнгән вакытта тапшырылмаган очракта, судка тиешле дәгъвалар бирүне.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 13 декабрь, 1215 нче
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары өчен
алынырга тиешле җир кишәрлекләре
исемлеге**

| Т/с | Кадастр номеры | Урнашу урыны | Мәйданы, кв.м | Милекчесе |
|---|---|---|---|---|
| 1. | 16:33:100812:254 | Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Ленино-Кокушкино авыл җирлеге | 70 530 | «Ак Барс Питрәч» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте |
| 2. | 16:33:100817:301 | Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Ленино-Кокушкино авыл җирлеге | 1 401 | |
| 3. | 16:33:000000:4303 | Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Ленино-Кокушкино авыл җирлеге | 1 094 | |
| 4. | 16:33:100817:299 | Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Ленино-Кокушкино авыл җирлеге | 76 079 | |
| 5. | 16:33:000000:4306 | Татарстан Республикасы, Питрәч муниципаль районы, Ленино-Кокушкино авыл җирлеге | 33 656 | |
| Барлыгы | | | 182 760 | |

______________________________